Тәкъдим ителә торган мәкалә иске татар әдәби теле истәлеге – Кадыйргали Бәкнең «Җамигъ эт-тәварих» («Елъязмалар җыентыгы») дигән әсәренең телен, аерым алганда, лексикасын тасвирлауга багышлана. Кадыйргали Бәк Касыйм ханының вәзире була һәм Уразмөхәммәд ханны Касыйм тәхетенә утырту хөрмәтенә Борис Годуновка «Мәдхия» яза. Шулай ук әсәргә Рәшидеддин Фазлуллаһның шул ук исемдәге хезмәтенең тәрҗемәсе кертелгән һәм Алтын Урда ханнары турында автор үзе язган дастаннар да урын алган. Бу әсәрнең барлык табылган исемлекләре Идел-Урал төбәгеннән килеп чыккан һәм Казан, Касыйм белән бәйле. 1602 елда Касыймда иҗат ителгән әлеге язма истәлек иске татар әдәби телендә язылуы, җанлы сөйләм үзенчәлекләре белән үрелеп баруы ягыннан аерылып тора. Кадыйргали Бәк үзе әсәрнең төрки телдә язылуын билгели. Бу тел катнаш характерда, анда Идел буе төрки теленә (XII–XV гасыр) барып тоташкан һәм чагатай традициясенең беркадәр тәэсирен кичергән әдәби формалар татар халык сөйләм теле элементлары белән яраша.



**Төп төшенчәләр:** дастан, иске татар әдәби теле, лексика, лексик-семантик төркемнәр


## Кереш

2023 ел Татарстан Республикасында Дастаннар елы дип игълан ителде. Күптән түгел Казанда «Кадыйргали Бәк дастаннарының теле» дигән темага диссертациябез нигезендә китап басылып чыкты [1]. Китапта тарихы Казан белән тыгыз бәйләнгән Касыйм ханлыгының төп язма һәйкәле булган төрки-татар тарихы өчен мөһим чыганакка лингвотекстологик һәм лингивистик анализ ясала. Әлеге китап белән беррәттән ТР Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Җәмигъ эт-тәварих»ның академик басмасы дөнья күрде. Анда әсәрнең биш исемлеге кергән. Басма яшь тикшеренүче Р. Алимов тарафыннан әзерләнгән [2]. Күптән түгел чыккан мәкаләләребезнең берсендә без Кадыйргали бәкнең «Җәмигъ эт-тәварих» әсәрендә лингвистик һәм текстологик характердагы бәхәсле мәсьәләләрне караган идек [3]. Әлеге мәкаләдә шушы ук әсәрнең лексикасына анализ ясала.

Теләсә кайсы төрки әдәби тел кебек үк татар теле тарихын өйрәнү дә язма истәлек-

ләрне җентекләп, лингвистик тикшерүдән башка мөмкин түгел, аларның һәрберсендә тел, аның тарихи үсешенең билгеле бер этабы сурәтләнгән.

XIX гасырда, күпсанлы дәреслекләр, сүзлекләр, ярдәмлекләр барлыкка килгәч, татар язма телен өйрәнүгә кызыксыну арта. XIX гасыр мәгърифәтчесе К. Насыйри үз хезмәтләрендә татар әдәби телен үстерү мәсьәләләренә игътибар итә. Күренекле татар диалектологы проф. Л. Җәләйнең диалектология, тарихи фонетика һәм морфология буенча хезмәтләрендә шулай ук татар әдәби теле барлыкка килү һәм үсү проблемаларына, кайбер әдәби нормаларның эволюцияләрен эшкәртүгә зур урын бирелә [4, 5 б.].

Татар милли әдәби теленең үсеше һәм барлыкка килү мәсьәләләрен тикшергән В.Х. Хаков тел тарихын XIII гасырдан башлап, чорларга бүлә [6, 13–17 б.]. Бу бүленеш халык тарихы фактларына нигезләнгән һәм әлегә тел фактлары белән аз тәэмин ителгән. В.Х. Хаков билгеләп үткәнчә, иске татар әдәби теленә борынгы төрки әдәби тел традицияләре һәм гарәп-фарсы алынмалары булу хас. Аның фикеренчә, Казан ханлыгы чорында «башка төрки телләрдән аермалы буларак, татар әдәби теленең лексик, фонетик һәм грамматик нормалары» формалашкан [6, 66 б.]. Ә Н.А. Баскаков болай дип яза: «Уйгур һәм иске үзбәк феодаль язма телләренең традицияләре иске татар телен халыкның массакүләм сөйләм теленнән аерган. Әмма әдәби телгә өстенлек итүче югары катламның аз гына өлеше файдалануына карамастан, бу тел XIX гасырга кадәр гамәлдә булган» [7, 161 б.].

Төрле үсеш чорларында татар әдәби теле һәм татар диалектларының үзара бәйләнеше турында мәсьәлә М.З. Зәкиев тарафыннан куела [8, 313–318 б.]. М.З. Зәкиев «язма телдә борынгы төрки традицияләр сакланып калган, алар гомумхалык сөйләменең берникадәр тәэсирен генә кичергәннәр» дип ассызыклап, «чит» әдәби телләрнең, аерым алганда, гарәп һәм фарсы телләренең көчле йогынтысын билгеләп үтә [8, 316 б.].

Татарча язылган эш кәгазьләренең телен тикшерүчеләр әлеге материалларда охшаш тел күренешләрен табалар. Бу охшашлык иске татар әдәби телендә урын алган кыпчак-угыз әдәби тел традицияләре саклану (XIII-XIV йөзләр) һәм Идел-Урал буйларының җанлы сөйләм теле үзенчәлекләренең язма әдәби телгә үтеп керү күренешләре белән аңлатыла [9, 51–66 б.].

Язма әдәбиятның төрле жанрларына караган иске язма истәлекләрне фәнни әйләнешкә кертү татар әдәби теле тарихын өйрәнүгә шактый дәрәҗәдә ярдәм итә ала. Шундыйларның берсе – Кадыйргали Бәкнең «Елъязмалар җыентыгы» әсәре (XVII гасыр).

Кадыйргали Бәкнең «Елъязмалар җыентыгы» 1602 елда Уразмөхәммәд хан заманында Касыйм шәһәрендә төзелә.

Композиция ягыннан Кадыйргали Бәкнең хезмәте өч өлештән тора:

1. Кереш. Рус патшасы Борис Годуновка мәдхия.

2. Рәшидеддиннең «Җамигъ әт-тәварих» әсәренең кыскартылган тәрҗемәсе.

3. Чыңгыз чыгышлы кайбер ханнарга һәм Алтын Урта чорында яшәгән Идегәйгә багышланган 9 дастаннан гыйбарәт төп өлеш.

Үзәктә – Уразмөхәммәдкә багышланган дастан, чөнки автор әлеге әсәрне Касыйм ханлыгында ул идарә иткән дәвердә язган. Әлбәттә, автор дастан дип атаган үзенчәлекле елъязмалар аеруча кыйммәтле. Бу урында әлеге терминның эчтәлеген бераз ачыкларга кирәк. Гадәттә, дастаннар дип лиро-эпик һәм героик-романтик поэмаларны атыйлар, мәсәлән, «Җөмҗөмә дастаны», «Бабахан дастаны», «Кисекбаш китабы» һ.б.; халык авыз иҗатына караган «Җик Мәргән», «Хан кызы Алтынчәч», «Идегәй» кебек тарихи риваятьләр һәм фантастик балладалар һ.б. Моннан тыш, дастаннарга нинди дә булса тарихи вакыйганы тасвирлый торган әсәрләрне дә кертәләр. Соңгыларына Кадыйргали Бәкнең елъязмалары керә, аларда аерым ханнарның тормышы һәм эшчәнлеге, аларның ата-бабалары, походлары, сугышлары, җиңүләре һ.б. тасвирлана.

Әлбәттә, Кадыйргали Бәк дастаннарының теле әдәби стиль үрнәге түгел.

Истәлекне тикшеренүчеләр аның телен билгеләүгә төрлечә якын килә.

И.Н. Березин, мәсәлән, «Елъязмалар җыентыгы» татар телендә язылган ди: «*Җалайыр* үз әсәрен татар телендә иҗат иткән, ләкин көнчыгыш язучыларының гадәте буенча, гомуми кулланыштагы телдә түгел, китап телендә язарга тырышкан» [10, 5 б.]. Истәлек теленә бирелгән мондый бәя белән В.В. Вельяминов-Зернов та килешә [11, 388 б.].

Ч. Вәлиханов фикеренчә, кулъязма «кыргыз-кайсац» (казакъ) теленә чагыштырмача якын булган чагатай телендә язылган. Әмма шул ук вакытта ул «“Бориска мәдхия” саф татарча язылган» дип билгеләп үтә [12, 159–164

б.]. А. Рәхим дә шуңа охшаш фикер җиткерә. «Китап бәян иткән телгә килгәндә, – ди ул, – бу тел Урта Азия әдәби теле башкача әйткәндә, чагатай теле белән тәңгәл диярлек. Әмма анда без, бер яктан, көньяк төрек, икенче яктан, Идел буе татар сөйләшләренең тәэсирен сизәбез, бу исә, гомумән, иске татар әдәби теленә хас күренеш» [13, 142 б.].

М.Г. Усманов исә «Елъязмалар җыентыгы»н «иске татар әдәби телендә язылган иң соңгы язма истәлекләрнең берсе» дип билгели [14, 65–68 б.].

Күпчелек тикшеренүчеләр әсәр «иске татар әдәби телендә язылган» дигән уртак фикердә. Әлеге галимнәр белән килешеп, без Кадыйргали Бәкнең «Елъязмалар җыентыгы» дигән әсәрен иске татар әдәби теле истәлеге дип саныйбыз. Фикеребез әсәр телендә урын алган гомумтөрки телгә хас традицияләр һәм Идел буена хас җанлы сөйләм теле үзенчәлекләренең урын алуы белән раслана.

**Тикшеренү материаллары һәм методлары**

Әлеге тикшеренү эшенең объекты – Кереш, «Бориска мәдхия» һәм оригиналь дастаннар. Мәкаләдә фактик материалны анализлаганда, күзәтү, чагыштырма, тасвирлама һәм семантик анализ методлары кулланылды.

**Фикер алышу**

Тикшеренү өчен алынган Кадыйргали Бәк әсәрләре безнең көннәргә өч исемлектә килеп ирешкән (хәзер инде биш исемлек мәгълүм).

Беренче исемлек (алга таба К литерасы белән биреләчәк) Т.40 номеры астында саклана (иске номерлары – Т.969 һәм Т.5028). КДУның көнчыгыш фәнни китапханәсе бүлегенә ул Г. Барудиның шәхси архивы белән тапшырыла.

Икенчесе – Ленинград исемлеге (алга таба Л литерасы кулланылачак) MSO-59 номеры астында саклана. Л исемлеге Казан университеты милкенә И. Хәлфинның шәхси китапханәсе белән тапшырыла, ә аннары ЛДУның фәнни китапханәсенә күчерелә.

Өченче исемлек (Р) фрагмент буларак тәкъдим ителә. Ул 1927 елда Татарстан АССРның Арча районы Кышкар авылда А. Рәхим тарафыннан табыла.

Алга таба бу хезмәттә истәлек теленең лексик составын (исемнәр, сыйфатлар һәм фигыльләр) лексик-семантик төркемнәргә бүлеп барлау максатка ярашлы дип табылды.

**Исемнәр**

<u>1. Кеше исемнәре.</u>

Дастаннарда 412 кеше исеме теркәлгән, нигездә, бу – ханнар, аларның хатыннары, хәрби җитәкчеләр исемнәре. Бу исемнәрнең күпчелеге гомумтөрки чыганаклы, алар хәзерге вакытта Идел буе татарларында, башкортларда, казахларда һәм башка төрки халыкларда очрый. Мәсәлән: *Ураз* [К 68б 9], *Урус* [К 60а 9], *Йадкәр* [К 65б 4], *Жумарт* [Л 144б 11], *Урақ* [Л 151а 1], *Таштимер* [Л 147а 3], *Булат* [Л 151б 11], *Тукай* [Л 151а 9], *Қутлуқыйа* [Л 149а 4] һ.б.

Күп кенә антропонимнар составында фигыль кулланыла: *Айбақ* [Л 144а 7] < *ай* + *бақ* «кара», *Туқтаға* [Л 143б 3] < *туқта* + *ға* юнәлеш килеш кушымчасы (бу бала соңгысы булсын дип теләүгә бәйле), *Итбаға* [Л 157б 5] < *ит* «эт» + *баға* «карый», *Җинай* [Л 146б 5] «җыя», *Қушай* [Л 147а 11] < *қушай* «парлы бул», *Килембирде* [К 61а 16] < *килем* + *бирде* «(Аллаһ) бирде» һ.б.

Антропонимнар составында лексик мәгънәсе ата-аналарның теләге белән бәйле булган күп кенә гадәти төрки сүзләр бар: а) ир баланы көчле, кыю күрергә теләү: *Таштимер* [Л 147а 3] < *таш* + *тимер*, *Булат* [Л 150а 3] < *булат* «корыч», *Тимерқутлу* [Л 146а 6] < *тимер* + *қутлу* «бәхетле», *Тимерхуҗа* [Л 147а 4] < *тимер* + *хуҗа*;

б) көтеп алынган дус пәйда булуга ышану: *Ишим* [Л 151а 9] < *иш* «дус» + *-им* 1 зат тартым кушымчасы, *Иш* [К 65б 3] «дус, юлдаш», *Буйдаш* [Л 150б 4] «тиң, тигез», *Қунақ* [К 62б 3], *Балтач* [Л 147а 30] < *балта* + *-чы*, *Бәхетле* [К 63б 5] һ.б.

Составларында хайван, җәнлек атамалары кулланылган исемнәр: *Күк бүре* [Л 144б 6], *Бикқундур улан* [Л 143а 10] < *бик* – титул + *қундур* «кондыз», *Қарилқурт* [К 62а 17, Л 147б 2] < *Қарил* + *қурт* «бүре» > Кариле ыруыннан, *Итбаға* [Л 157б 5] < *ит* «эт» + *баға* «карый, тәрбияли».

Текстта бер компоненты титулны аңлаткан сүзләр дә очрый: *бик*, *чура*, *қул*, *хаҗи*, *сәйед*, *шәйх*: *Башыбик султан* [Л 150б 1], *Шәйх-Әхмәд хан* [Л 146б 5], *Шәйх-Суфи бик* [К 69а 2], *Хаҗи-Әхмәд хан* [Л 143а 10], *Шәйх-Мамай мирза* [Л 143а 5], *Тимер-Хуҗа* [Л 147а 4], *Җанибик хан* [К 60а 17], *Җанчура бик* [Л 147б 2], *Хаҗи-Гәрәй хан* [Л 147а 2], *Бикқундур улан* [Л 143а 10], *Үзәк-чура* [Л 149б 4], *Сәйедқол султан* [Л 151а 8], *Қолгәли бай* [Л 147б 1], *Бәһлеwанқол султан* [К 65б 2], *Ақчуға* [К 62б 20], *Қулурус* [Л 147б 3] һ.б.

Тикшерелә торган истәлектә түбәндәге хатын-кыз исемнәре кулланылган: *Бикәй бикем* [Л 146б 2], *Чуйум ханым* [Л 153а 3], *Ханықсултан ханым* [Л 152б 9], *Уйшун бикем* [Л 146б 9], *Җағат бикем* [К 65б 15], *Бәхетле бикем*, *Йахшым бикем*, *Сунду ханым* [К 63б 9], *Афай бийем* [К 65а 12], *Дадым ханым* [Л 151б 1], *Абайқан бикем* [К 66а 7], *Татлы ханым* [Л 153а 2], *Дәwләтсолтан бийем* [К 65а 13], *Байым бикем* [Л 151а 8], *Җаникә* [Л 145б 1], *Гәүһәршад ханым* [Л 146б 10].

Елъязма характерында булганлыктан, дастаннарда исемнәр кыскартылмыйча, барлык титуллары белән тулысынча бирелгән. Мәсәлән: *Қуйручуқ хан* [Л 152а 3], *Бурундуқ хан* [Л 150б 9], *Усақ хан* [Л 150а 3], *Қучақ султан* [Л 146а 5], *Қулуш мирза* [Л 147б 4], *Үтәк бай* [Л 147а 11], *Җумарт хан* [Л 144б 11], *Суйунчақ хан* [К 65а 5], *Адwанаш хан*, *Тинмөхәммәд хан* [К 65б 4], *Илпарыс хан* [К 65а 17] һ.б.

Кеше исемнәрендә ыру атамалары да очрый: *Идигә Күчүк аның чурасы иде* [К 61а 6] *күчк* «эт», ягъни эт ыруыннан.

Дастаннарда урыс патшасы Борис Фёдорович Годунов һәм аның улының исеме берничә тапкыр кабатлана: *Барис Фидраwич* [К 67а 5], *Фидыр Барисаwич* [К 67а 5].

Төрки нигездә ата исеме (отчество) төшенчәсен бирү өчен, *улы ~ уғлы~ бине* (гарәпчә: улы) сүзләре кулланыла. Мәсәлән: *Қутлыкыйа уғлы Идигә Күчүк* [К 61а 6] «Кутлукыя улы Идигә Кучук», *Булғайыр хан бине Тулушиқ улан* [Л 144а 10] «Тулушик улан улы Булгаир хан».

2. Терминнар

а) иҗтимагый-сәяси төшенчәләр: *падишаһ* [Л 153а 10] «патша, король», *падишаһ хәзрәтләре* [Л 1а 6], *бик* [Л 145б 11] «бәк», *хан* [Л 144а 4] «хан», *хан хәзрәтләре* [Л 155б 11], *қурал* [Л 143б 8] «король», *аталық* [Л 155б 11], *имилдәш* [Л 155б 11], *бикем* [Л 146б 4] «кенәз хатыны», *ханым* [Л 153а 3] «хан хатыны», *чура* [К 61а 6] «чура, вассал», *қарачу* [Л 155б 10] «карачи», *алпағут-тылмач* [Л 154б 1–2] ~ *алпаwыт* [Л 155а 6–7] «илче», *султан* [Л 2б 4], *мирза* [Л 3б 11], *алтун ханум* [Л 151б 9], *уста* [Л 147а 11] «оста, балтачы», *хүкүм* [Л 153б 7] «карар», *йарлық* [Л 156б 8–9], *дәрман* [К 60а 6] «боерык», *тәхет* [Л 2б 9], *тәпуғ* [Л 4б 3] «хезмәт, буйсыну», *йығын* [Л 156б 2] «җыелыш», *туй* [Л 156а 3], *дуст* [Л 2а 8], *душман* [Л 2а 9], *йар* [Л 5а 1] «дус, көрәштәш», *халық* [Л 1б 10], *җәмәғәт* [Л 155а 4], *бай* [Л 156а 6], *йәтим* [Л 156а 6], *чығай* [Л 1а 11] «хәерче», *қара халық* [Л 154а 11], *тул* [Л 156а 7] «тол, ирсез хатын», *олуғлар* [Л 154б 3] «аксакаллар», *уғры* [Л 156б 8] «карак», *қарақчы* [Л 156б 8] «юлбасар», *хатун* [Л 151б 7], *қәмә* [Л 150а 8] «кәнизәк хатын», *урду* [Л 151б 9] «хатын, хатын-кыз», *ир* [Л 149б 5].

Шуларның кайберләренә җентекләп тукталыйк.

*Мирза*, *бик ~ би* – дворян катламы титуллары. *Бик ~ би* – ыруда иң хөрмәтле, иң өлкәне, калганнар мирза титулын йөртә.

*Қарачу*. Бу титулны зур затлы дворяннар нәселләренең вәкилләре йөрткән. Кагыйдә буларак, Казан, Кырым, Себер, Әстерхан, шулай ук Касыйм ханлыкларында дүртәр карачи булган [11, 417 б.]. Уразмөхәммәд Касыйм ханы дип игълан ителгән вакытта ике яктан икешәр карачи торган. Аларның исемнәре: *Җалайыр Қадырғәли бик*, *исбай манғут Симнай бик*, *арғун Чаныш бик*, *қыпчақ Туқай бик* [Л 156б].

*Аталық* < *ата* + *-лық* «булачак хакимнәрнең, падишаһларның әтиләрен алмаштырган кеше, остазлары». В.В.Вельяминов-Зернов мондый аңлатма бирә: «патша улларын тәрбияләүне күзәткән остазлардан алып, дәүләтнең югары сановникларына кадәр Аталык дип аңлаганнар» [11, 429 б.]. Бу титул Казан, Кырым, Ногай, Касыйм (Галикәй аталык васыяте, XVII гасыр), шулай ук Себер һәм Урта Азия ханлыкларында очрый. Тексттан мисал: *Қарачулары, аталық, имилдәшләре хан хәзрәтләренең үстүнә нәсарләр қылдылар* [Л 155б 10–11] «Карачи, аталык, имилдәшләр (Касыйм) бөек хан өстенә акчалар, бүләкләр сибәләр».

*Имилдәш*. Бу титулны югары катлам дворяннарының якын кешеләре йөрткән.

*Бикем* «кенәз хатыны». Мәсәлән, *бу икесенең анасы Абайқан бикем торур* [Л 155б 1] «Боларның икесенең аналары Абайкан бикем». *Ундан султан Алтун ханым Байым бикемдин туған ирде* [Л 151б 8–9] «Ундан солтанны Алтун ханум Байым бикем тапкан (тудырган)». Татар телендә бу титул туганлык термины буларак сакланган: *бийем*, *ақбийем* – «каенана, ирнең олы кыз туганы» [15, 29; 84 б.] һәм кеше исемнәре ясауда катнаша: Сөембикә, Тәңкәбикә, Гөлбикә.

Тексттан алынган мисалда хатын-кызның ике исеме булуы күренә: *Алтун ханум Байым бикем*. Соңгысы – Ундан солтанның әнисе исеме һәм титулы. Шигай ханның хатыны булып, ул инде беренче, затлы ханша – *Алтун ханум* титулын ала.

*Алтун ханум* титулы текстта тагын бер тапкыр очрый: Ундан солтанның хатыны, Ураз-Мөхәммәт ханның әнисе Татлы ханум *Алтун ханум* титулы белән аталган [Л 151б 10,11]. Уразмөхәммәднең хатыны да шул ук титулга ия булганлыгы мәгълүм [17, 91–92 б.].

б) хәрби терминнар: *муқәддимә ләшкәр* [Л 150а 2] «гаскәр башлыгы, командир», *баһадур* [Л 151б 3], *нуйан* [Л 157б 6] «гаскәр башлыгы», *қылыч* [Л 4а 1], *уқ* [Л 143б 5], *мылтық* [Л 153б 6], *йағы* [Л 151б 3] «дошман», *гәскәр* [Л 2б 7] ~ *ләшкәр* [К 65а 15] ~ *сипаһ* [Л 2б 7], *туқуш* [Л 150б 6] «сугыш», *уруш* [Л 145б 5] «сугыш», *булгақлық* [Л 152б 10] «фетнә», *санчыш* [Л 143б 3] «сугыш», *түмән* [Л 4б 3] «ун мең» һ.б.

Алтын Урдада бу титулларны үз ыругы яки кабиләсе белән элемтәләрен өзмәгән Чыңгыз ханга кадәр булган иске аристократия токымнары йөрткән; яки хәрби хезмәт өчен улус өлешен алган һәм хан билгеләгән хәрби җитәкчеләргә, яки хан, яки каган йортындагы аристократиянең йомышлы катламына да бу титуллар хас булган [16, 46–47 б.]. Мисаллар: *Җад Чингиз хан заманида Сартақ нуйан улур* [Л 157б 6] «бөек Чыңгыз хан вакытында Сартак гаскәр башлыгы булган», *суң тапқыр ул салды Йетем баһадурны* [Л 145а 2] «Соңгы тапкыр ул Йитим баһадурны (гаскәрләрен) тар-мар итә», *сақчы* [Л 4б 8] «сугышчы», *айачы* [Л 5а 6] «илче», *башлық* [Л 147а 10] «аз санлы сугышчылар башлыгы», *қараwыл* [Л 145а 4], *улан* [К 62а 10], *алып* [К 60б 14] «баһадир», *газамат бикләре* [Л 153б 5] «хәрби җитәкчеләр», *Қуңрат чирү бикләр* [К 62а 11] «гаскәр башлыклары булган Куңрат бәкләре».

Р.Г.Әхмәтьянов [17, 47; 48; 50 б.] фаразлаган *«берун кеше»* титулына тукталу урынлы булыр, әлеге титул «дәүләт чигендәге чит кабилә халкыннан булган сакчы» дигәнне аңлата. Бу сүзтезмә бары бер генә дастанда – Хаҗи Гәрәй хан дастанында гына очрый. Анда Хаҗи Гәрәйнең сукбайлыкта йөрүләре һәм аны ханлыкка чакыру турында сөйләнә. Аны хан тәхетенә һәр авылдан танылган кеше җитәкчелегендә унар кешедән җыелган бик күп халык юллап утырта. Тексттан бер өзек китерик: *Унта иле белән Нурма иленең Колурус, дағы Ғаликә бер ун кеше, Шәйх-задә иленең Қулуш мирза бер ун кеше дағы бер ун – Ақчура, Түрт өйленең Кибәк чирмеш Мөхәммәд бик-илле, Тәкле бер ун кеше, Иске йуртның Йадкар бай, Қасим Сәйед бай бер ун кеше, Қара дәwләт иленең Қунақ уста бер ун кеше...* [Л 147б 3–8; К 62б 1–3]. Хәзерге татар теленә тәрҗемәсе: «Унта һәм Нурма Кулурус авылларыннан, шулай ук Галикәдән якынча унар кеше белән, Шәйхзада авылыннан якынча ун кеше белән Кулуш мирза, шулай ук якынча ун кеше белән Акчура, Дүртөйледән Кибәк чиримис, Мөхәммәтбәк якынча илле кеше белән, Такле якынча ун кеше белән, җирле халыктан (Касыйм шәһәре) якынча ун кеше белән Ядкарь бай белән Касыйм бай һәм Касыйм-сәид бай, Кара Дәүләт авылыннан якынча ун кеше белән Кунак оста».

Тексттан күренгәнчә, *«бер ун кеше»* – титул түгел, ә аергычлы сүзтезмә, монда *«бер ун» (*якынча ун, унлап) – аергыч, *«кеше»* – аерылмыш.

Исемлекләрдә ул بر اون كشى өч сүздән торган сүзтезмә буларак бирелә, ә фаразланган *«берун кеше»* титулы برون كشى рәвешендә язылыр иде.

Бу фаразланган «*берун кеше*»нең этник составына килгәндә, «чит кабилә халкын»нан бары тик Кибәк черемис кенә очрый, ә калган барлык исемнәр төрки-татар чыгышлы һәм авыл исемнәре дә төрки.

в) дини терминнар: *пигәмбәр* [Л 149б 2], *аллаһ* [Л 153а 1], *мулла* [Л 155а 3], *дәнишманд* [Л 155а 3] «дини кануннарны белүче галим», *хафиз* [Л 155а 3] «Коръәнне яттан белүче кеше», *сәхәбә* [Л 156б 4] «көрәштәш», *әwлийәләр* [Л 156б 5] «изгеләр», *мустафа* [Л 156б 1,2] «сайлап алынган, Мөхәммәт эпитеты», *сәйед* [К 67б 14] «Мөхәммәт токымыннан һәм 12 имам», Казанда мондый титулга җирле мөселманнар башлыгы ия булган; *тәңре* [Л 143б 9], *хутба* [Л 155а 8] «дога», *мәсҗид* [Л 155а 2] «мәчет», *җин* [Л 3а 5] «җен», *пәри* [Л 3а 5], *бәндә* [Л 156а 7], *мусулман* [Л 149б 4].

г) туганлык терминнары: *аба wә аҗдад* (ар.) «ата-баба» [Л 152а 6], *барча уруг-қарындашлары* [Л 152а 7] «барлык ата-бабалар», *улуг бабасы* [Л 153а 6] «ата ягыннан баба», *бабасы* [Л 153б 9] ~ *уз бабасы* [Л 153б 7] «ата», *бабасы* [К 62б 10] «бабай», *ата-ана* [Л 157а 4,5], *атасы* [Л 152б 7, К 60б 10, К 65б 15], *анасы* [К 63б 5, К 61а 2, Л 151а 10], *агасы* [Л 148а 8] «олы абыйсы», *энесе* [К 63б 15, К 60б 17], *угланлары* [Л 150а 9, Л 152б 10] «ир балалары», *углы* [К 65б 1], *бине* [Л 147а 3] ~ *ибе* [К 65а 8] «ул», *қызы* [Л 151б 1, К 61а 16], *қуда* [К 65а 11], *қарындаш* [Л 146б 2] «кыз туган», *бутун* [Л 152а 8] «токым», *уруг* [Л 152б 1] «ыру», *нәсел* [Л 142б 11], *қаум* [К 63б 9] «халык, милләт».

3. Этнонимнар

*Кыпчак* [Л 155б 3] «кыпчак», *угуз* [Л 157б 1] «угыз», *чирмиш* [Л 147б 5] «черемис (мәҗүси марилар)», *нимеч* [Л 2а 10] «немец», *фарс* [Л 157а 6] «фарсы», *түрк* [Л 157а 6], *урус* [Л 154б 11], *татар* [Л 154б 11], *чиркәс* [К 60а 5], *мажар* [Л 2а 7] «мадьяр», *бачкыр* [Л 1б 4, К 60а 12, К 60а 14] ~ *башгырд* [Л 142б 1, Л 142б 6] «башкорт», *буләр* [Л 142а 1] «болгар кабиләсе», *тагда – түмән, кырда – чиркәс, уйда – иштәк* [Л 1б 3] «калкулыкта – туман, далада – черкес, түбәнлектә – иштәк».

Ыру һәм кабилә атамалары.

*Җалайыр* [Л 157б 7], *тукуз-сары* [Л 150б 2] «Тукуз-сары ыруы», *тарак тамгалы җалайыр* [Л 157а 5], *катагын* [К 69а 8,10] «катагин ыруы», *алаҗ менгу* [Л 148а 4] «Алаҗ менге» кабиләсе исеме, *кум Куңрат* [К 63б 9] «Куңрат ыруы», *Исбай маңгут Симнай бик* [Л 155б 3] «Исбай маңгут ыруыннан Симнай бәк», *аргун Чаныш бик* [Л 155б 1] «Аргун ыруыннан Чаныш бәк».

4. Административ бүленеш берәмлекләре

*Улус* [К 60б 2, К 60а 12, К 64а 1] «улус», «өлкә», *wилайәт* [Л 146б 8, Л 1б 6] «ил», *мәмләкәт* [Л 2а 5, Л 3б 7, Л 4б 4] «ил, держава», *Ак-урда* [Л 5а 3] «Ак урда», *йурт* [Л 2б 6, К 65а 16] «ставка», *кәлгә* [Л 2а 10, Л 2б 2] ~ *шәһәр* [Л 3б 8, Л 4б 6] ~ *кәнт* [К 60б 7], *ил* [К 62а 15], *бәргаһ* [Л 5а 3] фарсыча «патша сарае».

5. Топонимнар

Борис Годуновка багышлауда автор патшаны зирәк кенә түгел, ә куәтле, дөньякүләм хаким итеп тә сурәтли, аның кул астына русныкы булмаган күп кенә җирләр кергән; Рус дәүләтенең күп илләр, халыклар белән элемтәләре турында әйтелә. Илләр, халыклар, державалар исемнәре: *Шам* [К 62б 11] «Сирия», *Рум wиләйәте* [Л 1б 4] «Византия», *Гыйрак* [Л 4а 5] «Ирак», *нимеч курал wиләйәте* [Л 1а 8] «немец короленең җирләре», *Кырым билә Түрк* [Л 2б 1–2] «Кырым белән Төркия», *Хытай* [Л 4а 5] «Кытай», *Җабылса билән Җабылка* [Л 1б 5] «Япония», *Ибир-Сибир* [Л 142а 11] «Көнбатыш Сибирь», *Дәште Кыпчак* [Л 142б 1], *Буләр-Башгырд* [К 60а 9] «биләр һәм башкорт җирләре», *Узбекийә* [Л 144а 1] «Үзбәк җирләре», *Тәшкәнд-Түркестан wилайәте* [Л 144а 11] «Төркестан», *Чагат wилайәте* [Л 150б 2] «Чагатай улусы» һ.б.

Шәһәр исемнәре: *Камкәнт* [Л 149б 5] «Камканд», *Мадаин* [К 62б 17] «Мәдинә», *Утрар* [К 60б 6], *Мәскәw* [Л 3б 8], *Кирмән* [Л 154а 8] «Касыйм», *Ташкәнд* [Л 144а 11], *Үргәнеч* [Л 149а 8], *Күмүшкәнт* [К 66а 17], *Сарайчык* [Л 152б 8] һ.б.

Елга, күл исемнәре: *Идил* [Л 149а 4], *Җайык* [Л 143б 1], *Иссиг күл* [К 60б 6], *Тикәлек* [К 60б 6,7], *Иләк суwы* [Л 143б 1].

Тау исемнәре: *Алатаг* [К 60б 1] «Алатай», *Йаланлы түбәдә* [К 66а 5] «Еланлы түбә тавы», *Тимер капу* [Л 142б 2] «Тимер капка».

Авыл исемнәре: *Упмас иле* [Л 147а 10], *Чапчык иле* [Л 147б 1], *Сарда иле* [Л 147б 1], *Тимерче иле* [Л 147б 9], *Кәче иле* [Л 147а 11], *Түрт өйле* [Л 147б 5], *Кара Гәйшә* [Л 147б 9], *Кара Дәwләт* [Л 147б 7], *Шабшы иле* [Л 147б 2], *Үнтә иле* [Л 147б 3], *Нурма иле* [Л 147б 3], *Шәйхзада иле* [Л 147б 4], *Султан иле* [Л 147а 10], *Хәйрби иле* [Л 147б 8] ~ *Бирнә иле* [Р] ~ *Хәйрле* [К 62б 4] һ.б.

Бу авылларның исемнәре Хаҗигәрәй хан дастанында китерелгән. Шул авыллардан җыелган кешеләр Хаҗигәрәйне тәхеткә утырткannar.

А. Рәхим күрсәтелгән авыл исемнәренең элеккеге Казан ханлыгы чикләрендә очравына игътибар итә. Казан тәхетенә берәр ханның шулай күтәрелүе булганмы-юкмы – бу хактагы сорауга ул ачыклык кертмәгән. Әлеге вакыйганың һичшиксез Казанда булганлыгын раслаган Х. Хисмәтуллинга каршы чыгып, М. Усманов: «...генеалогик мәгълүматлар Хаҗигәрәйне Казан ханы итеп игълан итәргә мөмкинлек бирми» дип яза [14, 81-82 б.].

6. Тере булмаган табигать

а) ландшафт: *таш* [Л 155а 2], *йер* [Л 149б 7] «урын», *тиңез* [Л 2а 2] «диңгез», *таг* [Л 1б 10] «тау», *су* [К 60б 5], *дәрйа* [Л 3б 2] «диңгез, зур су», *инҗү* [Л 4а 4] «энҗе», *бүртә* [Л 143б 2] «калкулык», *йул* [К 60а 9] һ.б.

б) астрономик төшенчәләр: *ай* [Л 3а 11], *күн* [Л 4а 8] «кояш», *җиһан* [Л 5а 8] ~ *дүнйа* [Л 1а 9], *күк* [Л 5а 3].

в) табигать күренешләре: *йагмур* [Л 3а 9] «яңгыр», *булут* [Л 3а 4] «болыт», *йаруклук* [Л 5а 4] «яктылык».

г) вакыт төшенчәләре: *абадел-абадкәчә* [Л 157а 2] «мәңге, очсыз-кырыйсыз», *йыл* [Л 2а 3] ~ *сал* [К 65б 9] ~ *сәнә* [Л 147а 9] «ел», *ай* [Л 1а 11], *кыш, йаз* [Л 1а 11], *һәфтә* [Л 154б 4] «атна», *кичә* [Л 4а 7] «төн», *күндүз* [Л 156а 10] «көн», *күн* [Л 4а 5] «көн».

Ай исемнәре: *зөлхиҗә* [Л 154б 8], *хәмәл* [Л 153б 2], *берак* [Л 153б 2], *шәwwәл* [Л 154б 4], *җөмәди-ал-ахыр* [Л 147а 9], *мухаррам* [К 67а 3], *рамазан* [К 67а 3].

7. Тере табигать

а) Үсемлекләр дөньясы: *йапрақ* [Л 1б 7] «яфрак», *ашлық* [Л 3а 8] «бөртеклеләр», *йер чәчәге* [Л 5а 3], *ут* [Л 3а 7] «үлән», *ағач* [Л 3а 7], *сәчәкләр* [Л 3а 8] «чәчәкләр», *чүп* [Л 3а 7] «чүп үлән» һ.б.

б) Хайваннар дөньясы: *сычқан* [Л 153б 2] «тычкан», *туңқуз* [Л 153б 2] «дуңгыз», *арслан* [Л 3б 11], *йылқы* [Л 156а 4] «елкы / ат», *қуй* [Л 156а 4] «сарык», *сығыр* [Л 156а 4] «сыер», *җанwар* [Л 3а 5], *туйур* [Л 3а 5] «кошлар», *ат* [Л 145б 6], *қуйан* [К 69а 15]. *Сычқан*, *туңқуз*, *йылқы*, *қуйан* төрки хайван календаренда ел атамалары булып йөргәннәр.

в) тән төзелешенә караган сүзләр: *уң қул* [Л 156б 7], *сул қул* [Л 157б 11], *баш* [Л 4а 10], *эч* [К 63б 12], *тән* [Л 4б 10] һ.б.

8. Киңлекне, мәйданны билгели торган сүзләр

*Түгәрәк* [Л 1а 8–9], *эч* [Л 3а 11], *уң йан* [Л 149а 10], *тараф* [Л 5б 1], *айналасы* [Л 1а 8] «әйләнә», *йақ* [Л 155а 9], *мәгрип* [Л 5а 6] «көнбатыш», *мәшриқ* [Л 5а 6] «көнчыгыш», *шималь* [Л 5а 7] «төньяк», *җәнүб* [Л 5а 7] «көньяк», *ахыр* [Л 153б 2] ~ *тамам* [Л 153б 11], *уртасында* [Л 1б 9], *ара* [Л 4а 8], *үст* [Л 155а 10] «өс», *йете әқлим кишwәр* [Л 1б 1] «җирнең җиде кыйтгасы» һ.б.

9. Абстракт төшенчәләр

*Ағры* «авырту», *ат ~ нам* «исем», *азат* «ирек», *дәwләт* «бәхет», *эш*, *йад* «хәтер», *мал* «мөлкәт, байлык», *гәделлек*, *тарлық* «уңайсызлык», *тамаша*, *михнәт*, *сәбәп*, *бәһа*, *файда*, *дустлуқ* «дуслык», *баһадурлуқ* «геройлык», *белек* «белем», *күрүк* «көнчелек», *ачлық-сусалық* «ачлык һәм сусау», *асайыш* «тынычлык», *иқбал* «уңыш, бәхет», *аманлық* «иминлек», *иҗазат* «рөхсәт, илтифат», *морад* «теләк», *мәҗал* «көч», *күңел*, *җан*, *қуwәт wә шәwкәт* «көч һәм батырлык» һ.б.

10. Әдәбият терминнары

*Мисраг түрки* «төрки ярымшигырь», *сүз*, *китап*, *хикәйәт*, *дастан*, *истинабат* «уйлап чыгару, уйлап табу», *сурәт*, *тәwарих* «тарих, тасвирлау», *фасыл* «бүлек», *кәтибә* «язучы», *риwайат*, *нусхә* «экземпляр», *Чыңгызнамә китабы* һ.б.

**Сыйфатлар**

а) Асыл билгеләр, төсләр: *ақ урдаң* [Л 5а 3] «ак урда», *ала бәргаһ* [Л 5а 3] «төрле төстәге патша сарае», *олуг бик* [Л 1а 7] «бөек бәк», *йахшы атың* [Л 1б 5] «синең яхшы исемең», *тулуқ* [Л 4б 7] «тулы», *мундаг* [Л 4а 3] «мондый», *қатыг туқушлар* [Л 149б 11] «авыр сугышлар», *кәлитә ханлар* [Л 150б 8–9] «йогынтылы ханнар», *амра’* [Л 157б 9] «хөрмәтле, сөекле» һ.б.

б) Халәтнең сыйфаты, билгесе: *фани дөнйа*, *дәwләтле тәхтең* [Л 2б 10] «бай тәхетең», *ач арслан* [Л 3б 11], *күкдәге болыт* [Л 5а 3], *йалгуз* [Л 61а 3] «ялгыз» һ.б.

**Фигыльләр**

а) Хәрәкәт фигыльләре: *йүр-* «йөр-», *қачып йүр-* «качып йөр-», *йибәр-* «җибәр-», *кил-*, *атланып чық-*, *атлан-*, *мен-*, *эзләп тап-*, *килеп төш-*, *қач-*, *алып кил-*, *бар-*, *кил-*, *үт-*, *гиз-*, *учра-* «очра-», *йет-* «барып җит», *күтәр-*, *үтүп бар-* «үт-», *түш-* «төш-» һ.б.

б) физиологик халәт фигыльләре: *тетрә-* «калтыра-», *телә-*, *wафат тапты-* [Л 151б 6] «үлде», *ишет-*, *шаһид бул-* «һәлак булу», *үкүн-* «үкен-», *үл-*, *йад қыл-* «искә төшер-», *күр-*, *йәшә-*, *wафат бул-* һ.б.

в) торыш (халәт) фигыльләре: *бел-*, *бул-*, *хасил бул-*, *бузул-* «бозыл-», *йарат-*, *йарлықа-* «кичер-», *түкән-* «үл-», *тапуг ит-* «буйсындыр-», *герифтарлық чик-* «ялын-», *хайат торур-* «яшә-», *уқы-*, *әсир ит-* «кулга ал-», *иксемәс-* [Л 5а 11] «кипмә- (с) / корыма-(с)», *йулуқ-* «каршыга очра-», *агала-* «олыла-», *сын-*, *қаршу тур-* «каршы тор», *чирқамыш қыл-* «коен-», *туң-* һ.б.

г) нинди дә булса предметка юнәлгән хәрәкәт фигыльләре: *ал-*, *сач-* «чәч- (түк-)», *билә-* «идарә ит-», *тут-* «тот», *тик-* «барып җит-, кагыл-», *сал-* «төзе-», *йық-* «буйсын-», *сөһүргал қылып бир-* «бүләкләр өләшеп чык-», *ач-*.

д) сөйләм фигыльләре: *аwаз бир-* «тавыш бир-», *хәбәрлә-*, *ай-* «сөйлә-», *ти- ~ ди-* «әйт-», *тип айт-* «әйт-», *агаз қыл–* «кычкырып әйт-», *хәбәр қыл–* «хәбәр ит», *риwайат қыл-* «сөйлә-».

**Нәтиҗәләр**

1. Кадыйргали Бәк дастаннарының лексик составын тикшерү аларда кулланылган сүзләрнең төп өлешен төрки тамырлы берәмлекләр тәшкил итүен күрсәтә. Терек һәм терек булмаган табигатьнең, кешелек җәмгыятенең күп кенә күренешләре, асыл билгеләре, сан, алмашлык, шулай ук әйберләр һәм тереклек ияләренең хәрәкәтләре, халәтләре төрки сүзләр белән белдерелгән, аларның күпчелеге борынгы һәм урта төрки истәлекләрдә дә теркәлгән.

2. Лексиканың бер өлешен (41%) гарәп-фарсы алынмалары тәшкил итә. Алар дини, хәрби терминнар составында аеруча күп очрый; кеше исемнәренең яртысыннан артыгы – гарәп-фарсы сүзләре. Кайбер фарсы алынмалары (*андаз* «атарга», *тирандаз* «снайпер», *ан* «теге», *ин* «бу», *бозорг* «бөек») шушы истәлеккә генә хас, бу – Кадыйргали Бәкнең фарсы теленнән төрки телгә тәрҗемә эшчәнлеге белән бәйле. Алынмаларның зур өлеше язылыш рәвешләре белән төркичәгә яраклаштырылган. Алар күпчелек төрки истәлекләр өчен уртак һәм хәзерге төрки телләрдә киң кулланыла.

3. Рус алынмалары катламы, башлыча, антропонимнардан, этнонимнардан һәм топонимнардан гыйбарәт. Әлеге алынмалар белән истәлектә рус сүзләренең татар теленә үтеп керүенең башлангыч чоры теркәлгән. Бу берәмлекләрнең үзенчәлеге шунда ки, алар Россиягә кушылган һәм буйсындырылган Касыйм ханлыгының лингвосоциаль хәлен чагылдыралар. XVII гасыр башында Урта Азия истәлекләрендә рус алынмалары булмаган. Русизмнар бер генә юл белән – татарларның рус халкы белән турыдан-туры аралашуы аша үтеп кергән.

**Әдәбият**


1. Хисамиева З.А. Язык дастанов Кадыр Али-бека. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2022. 244 с.
2. Кадыр Али-бек. Джами ат-таварих. Факсимиле рукописи / авт. издания текста, исследования, критического текста, перевода с тюрки, глоссария Р. Алимов; под науч. ред. И.М. Миргалеева. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2022. 544 с
3. Хисамиева З.А. Сочинение Кадыр Али-бека: к вопросу о некоторых дискуссионных аспектах // Золотоордынское обозрение. 2023. Т. 11, № 2. С. 258–265. DOI: 10.22378/2313-6197.2023-11-2.258-265 EDN: AHXDOP
4. Җәләй Л. Татар диалектологиясе. Казан, 1947. 137 б.
5. Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан, 1954. 108 б.
6. Хаков В.Х. Развитие татарского национального литературного языка и его стилей. АДД. Алма-Ата, 1971. 60 с.
7. Баскаков Н.А. Тюркские языки. М.: Акад. наук СССР, Ин-т языкознания, 1960. 242 с.
8. Закиев М.З. О взаимоотношении татарского литературного языка и диалектов в различные периоды их развития. // Лингвистика, география, диалектология и история языка. – Ереван: Изд-во АН Арм. ССР, 1976. С. 313–318.
9. Тумашева Д.Г., Усманов М.А., Хисамова Ф.М. Об особенностях развития деловой письменности. // Советская тюркология. 1977. №3. С. 51–66.
10. Березин И.Н. Библиотека восточных историков, Шайбаниада, т. I; Сборник летописей, татарский текст, т. II, ч. 1. Казань, 1849–1854. 92 с.
11. Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о Касимовских царях и царевичах, чч. 1–4. СПб., 1863–1887.
12. Валиханов Ч.Ч. Извлечения из جامعالتواريح . – Собр. соч. в 5-ти томах, т.1. Алма-Ата: Главная редакция Казахской советской энциклопедии, 1961, с. 159–164.
13. Рахим А. О новом списке татарского исторического сочинения XVII века. – Вестник научного общества татароведения. Казань, 1927, №7. С. 133–148.
14. Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. Казань: изд-во КГУ, 1972. 223 с.
15. Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан: Тат. кит. нәшр, 1969. 647 с.
16. Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М.: изд-во МГУ, 1973. 180 с.
17. Әхмәтҗанов Р. «Җәмигь-әт-тәварих»ның оригиналь өлешендәге этносоциаль терминнар турында // Татар теле һәм әдәбияты. 6 нчы китап. Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. Б. 44–50.


# ЛЕКСИКА ДАСТАНОВ КАДЫР АЛИ-БЕКА


**Замзамия Ахияровна Хисамиева**,
Набережночелнинский государственный педагогический университет,
Россия, 423806, г. Набережные Челны, ул. им. Низаметдинова Р.М., д. 28,
zolotayaorda.centr@mail.ru.



Статья посвящена описанию лексики памятника старотатарского литературного языка – сочинению Кадыр Али-бека, условно названному «Джами ат-таварих» («Сборник летописей»). Кадыр Али-бек был везирем Касимовского хана и в честь интронизации Ураз-Мухаммеда на касимовском престоле написал «Хвалу» царю Борису Годунову. Также в сочинение включен

перевод одноименного труда Рашид ад-Дина и дастаны о золотоордынских ханах, написанные самим автором. Все найденные списки этого сочинения происходят из Волго-Уральского региона и были связаны с Казанью и Касимовым. Данный письменный памятник, созданный в 1602 году в Касимове, выделяется тем, что в нем переплелись и смешались грамматические формы и лексика различных диалектов тюрко-татарского языка. Сам Кадыр Али-бек языком своего сочинения называет тюрки. Этот язык носит смешанный характер, в нем сочетаются собственно литературные формы, восходящие к поволжскому тюрки (XII–XV в.) и испытавшие некоторое влияние чагатайской традиции, с элементами татарского народно-разговорного языка XVI–XVII вв.

**Ключевые слова:** дастан, старотатарский язык, лексика, лексико-семантические группы